# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **10.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге составына керүче
Мәллә-Тамак торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Мәллә-Тамак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Урам юлларын кыш коне карап тоту;
- Урам юлларын җәй көне карап тоту;
- Урам утларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү;
- Юллар төзелеше һәм ремонты;
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
- Массакүләм мәдәни чараларны оештыру һәм үткәрү. Халык күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү;
- Җирлекләрнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;
- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Җирлек территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http://muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Мәллә-Тамак авылы, Кооператив урамы, 32а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәллә-Тамак авыл җирлеге башлыгы И.З.Ахмадуллин